**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с. Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел.(85552)3-44-22,факс(85552)3-44-14,E-mail:mail.Aktanish@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

________________ № _____

**2022 елга «Актаныш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге гомуми белем бирү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында**

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, «Актаныш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «Актаныш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең гомуми белем бирү оешмаларын норматив финанслауны кертү турында» 2019 елның 01 ноябрендәге ПР-257 номерлы карары нигезендә, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. 2022 елга кушымтада бирелгән түбәндәгеләрне расларга:

«Актаныш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең гомуми белем бирү оешмалары һәм гомуми белем бирү интернат мәктәпләре каршындагы интернатларда тәрбияләнүчеләрне тотуга норматив чыгымнар;

2. «Актаныш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең финанс-бюджет палатасына әлеге карарның 1 пункты белән расланган белем бирү оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә белем бирү оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы Р.М.Шакировага йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе — И.И.Габдулхаев

Расланган
«Актаныш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән
«__» ____________ 20___ № ___

**«Актаныш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең гомуми белем бирү оешмалары һәм гомуми белем интернат мәктәпләре каршындагы интернатларда тәрбияләнүчеләрне тотуга норматив чыгымнар**

| Гомуми белем бирү оешмасының тибы һәм төре | Территориаль дислокация | Елга бер тәрбияләнүчегә норматив чыгымнар, сум |
|---|---|---|
| Гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернат | авыл җирлеге | 98753 |
| Гомуми белем бирү интернат-мәктәбе | авыл җирлеге | 148363 |